КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 март г.Казань № 222

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды турында» 2018 ел, 14 декабрь, 1133 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды турында» 2018 ел, 14 декабрь, 1133 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 сентябрь, 830 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды турындагы нигезләмәне расларга.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына киңлек мәгълүматларын һәм киңлек мәгълүматлары турындагы белешмәләрне Учреждениегә бирүне тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына аларны бирүне гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.»;

әлеге карарга Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин